**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СПАССКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.08 **2018 год** г. Болгар **№** 489

**“Янгын чыгу, су басулар, техноген сәбәпләр
һәм башка бәла-казалар чыгу нәтиҗәсендә, мөлкәтен
югалткан халыкка ТР Спас муниципаль районы бюжеты исәбенә
материаль ярдәм күрсәтү турында”гы Положениене раслау
турында**

Янгын чыгу, су басулар, техноген сәбәпләр яки башка бәла-казалар нәтиҗәсендә мөлкәтен югалткан гражданнарга (гаиләләргә) социаль ярдәм күрсәтү максатында, “Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставының 46нчы маддәсенә нигезләнеп, Спас муниципаль районы Башкарма комитеты чыгарган

КАРАР

1. “Янгын чыгу, су басулар, техноген сәбәпләр һәм башка бәла-казалар чыгу нәтиҗәсендә мөлкәтен югалткан халыкка ТР Спас муниципаль районы бюджеты исәбенә материаль ярдәм күрсәтү турында” гы Положениене кушымта нигезендә расларга.
2. “Янгын чыгу сәбәпле, Спас муниципаль районы халкына материаль ярдәм күрсәтү турында”гы 2011 елның 28 октябрендә расланган 692нче положениене (2012 елның 13 гыйнварында 13нче номерлы һәм 2013 елның 14 гыйнварында үзгәрешләр кертелгән 15нче номерлы положениеләрне) үз көчен югалткан дип санарга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны ТР Спас муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

Спас муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесе В.А.Осокин.

ТР Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты
Карарына 1нче кушымта
№ 489 от“23 “ 08 2018 ел.

## Янгын чыгу, су басулар, техноген сәбәпләр һәм башка бәла-казалар чыгу нәтиҗәсендә мөлкәтен югалткан халыкка ТР Спас муниципаль районы бюджеты исәбенә материаль ярдәм күрсәтү турындагы положение.

### 1. Гомуми положениеләр

1.1. Әлеге Положение нигезендә ТР Спас муниципаль районы гражданнарына (гаиләләргә) билгеләү шартлары, тәртибе һәм күләме билгеләнә.

1.2. Гражданнарга (гаиләләргә) материаль ярдәм мөлкәтне түбәндәге очракларда:

- янгын, су басулар, техноген сәбәпләр яки башка бәла-казалар нәтиҗәсендә торак, ишегалды корылмаларына тулысынча яки өлешчә зыян килгәндә күрсәтелә;

1.3. Материаль ярдәм ТР Спас муниципаль районы территориясендәге яшәү урыны буенча теркәлгән торак бина хуҗаларына янгыннан, су басулардан, технонег сәбәплердән яки башка бәла-казалар нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга (гаиләләргә), шулай ук торак бина милекчеләре булмаган, әмма әлеге торак биналарда теркәлгән кешеләргә күрсәтелә.

1.4. Материаль ярдәм гариза тапшырылган вакытта гамәлдә булган хезмәткә түләүнең минималь күләменнән артмый, бу очракта 2нче индекс кулланыла.

1.5. Торак бинага яки мөлкәткә тулысынча зыян килгән очракта хезмәткә түләнең минималь күләменә карата 2нче индекс кулланыла;

торак бинаның бер өлешенә зыян килгәндә хезмәткә түләүнең минималь күләменә карата 1нче индекс кулланыла;

ишегалды корылмаларына зыян килгәндә хезмәткә түләүнең минималь күләменә карата 0,5 индексы кулланыла.

1.6. Материаль ярдәм Спас муниципаль районының резерв фонды исәбенә күрсәтелә.

1.7. Гражданнарга (гаиләләргә) Спас муниципаль районы исәбенә материаль ярдәм бер тапкыр күрсәтелә. Икенче тапкыр материаль ярдәм күрсәтү каралмаган.

### Материаль ярдәм күрсәтү тәртибе

2.1. Материаль ярдәм гражданинның яки аның опекуны, попечителе, законлы башка вәкиленең материаль ярдәмгә ни сәбәпле мохтаҗ булуын ачыклап язган гаризасы буенча күрсәтелә. Гариза белән бергә әлеге положениедә расланганча, милеккә зыян килүен раслаучы документларны да тапшырырга кирәк.

2.2. Гражданнарның материаль ярдәмгә мохтаҗ булулары турындагы гариза ТР Спас муниципаль районы башлыгы исеменә яки ТР Спас муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрелә. Материаль ярдәм күрсәтү турында карар кабул ителгән документларның дөреслеге өчен документларны тапшырган кеше яки аның законлы вәкиле җавап бирә.

2.3. Гражданнарның гаризасы тиешенчә теркәлгәннән соң 30 көн эчендә карала.

2.4. Материаль ярдәм алырга теләгән кеше гариза белән бергә милкенә зыян килүе турындагы фактны раслый торган документлар: тиешле хезмәтләрнең белешмә-справкаларын, вәкаләтле орган яки комиссияләрнең китерелгән зыянны күрсәтелгән беркетмә карарларын да тапшырырга кирәк.

2.5. Исәп-хисап счеты нигезендә материаль ярдәм күрсәтү турындагы карарны ТР Спас муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе чыгара.

Материаль ярдәмне ТР Спас муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы түли.

Материаль ярдәм гражданин яки аның законы вәкиле язмача мөрәҗәгать иткәннән соң 30 көн дәвамында түләнә. Кайбер очракларда гаризаны карау срогы 30 көннән артып китәргә мөмкин. Бу хакта гражданинга (гаиләгә) хәбәр ителә.

2.6. Янгын, су басулар, техноген сәбәпләр яки башка бәла-казалар нәтиҗәсендә зыян күрүчеләргә материаль ярдәм күрсәтү өчен акчаны Финанс-бюджет палатасы ТР Спас муниципаль районының муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүченең исәп-хисап счетына күчерә. Акчаның- счетка күчерелүе турында Башкарма комитет гариза тапшыручыга хәбәр итә.

Материаль ярдәм акчасы шәхесне ачыклаучы документ яки материаль ярдәм акчасын күчерү өчен реквизитлар күрсәтелгән документ булганда гына түләнә.